

Беренче январда татар әдәбияты классигы, шагыйрь, драматург Һади Такташнын тууына 125 ел тулды. Әлеге унайдан татар жәмәгатьчелеге шагыйрьнен Казанда урнашкан һәйкәле янында жыелды, дип яза Интертат корреспонденты Золфия Шәвәлиева. Чарада Татарстан Язучылар берлеге, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Галимжан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты вәкилләре катнашкан.      Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин быел шагыйрьнен туган авылы, Мордовия республикасы Сыркыды авылында урнашкан музеен тозекләндерәчәкләре турында сойләгән. Дамир Натфуллин сvзләренчә, әлеге эшне Татарстан Мәдәният министрлыгы башкарачак. Ул болай дигән:

- Бер яктан, әлеге музей Мордовия республикасында урнашкан, ләкин, шул ук вакытта, без дә читтә кала алмыйбыз. Безнен Муса Жәлил һәм башка бик кvп боек шәхесләребез Татарстаннан читтә туып vскән, һәм аларнын туган якларында Татарстан республикасы ярдәме белән музейлар тозелгән, бу – безнен бурыч.

Дамир Натфуллин быел Татарстанда Һади Такташка багышланган бик кvп чаралар узачагын белдерде:

- 2026 елнын беренче конен боек шәхесебезнен юбилее белән башлап жибәрәбез. Һади Такташ ижаты безнен әдәбият тарихына алтын хәрефләр белән язылган. Беренче гыйнвар иртәсе булса да, аны искә алырга кvпме халык жыелды. Без анын исемен, шигырьләрен онытырга тиеш тvгел. Быел анын исеменә багышлап бик кvп чаралар узачак. Казанда анын һәйкәле, исемендәге урам бар, топ максатыбыз – анын исемен мәнгеләштерv, торле чаралар уздыру һәм әсәрләрен яшьләргә, балаларга житкерv. 2026 елда әлеге эшне башкарачакбыз, – диде ул.

(Кыскартып алынды, тулырак: https://intertat.tatar).